КАРАР

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеге Советының "Физик затлар милкенә салым турында" 2014 елның 10 ноябрендәге 20 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 30 сентябрендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. «Физик затлар милкенә салым турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Актанышбаш авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 ноябрендәге 20 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 пунктның 3 пунктчасының дүртенче абзацында «бер торак бина (торак йорт)» сүзләрен «бер торак йорт» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан, рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында “Актанышбаш авыл җирлеге” бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Л.Г.Хәйдәрова